1/92
Январь

ISSN 0868-4545

Салават күпере



Узган елгы 3 нче санybыздa без укучыларыбызга анкета сораулары тәкъдим иткән идек. Журналханәбез бик күп хатлар алды. Хәзер сезне шуларның берничәсе белән таныштырабыз.

Җиде куа



● «Салават күпере» нәниләрнеке генә түгел, ул минем кебек шәһәр мәктәпләрендә урысча укучы татар балаларына үз телләрен өйрәтүче зур ярдәмлек тә. Минем өчен журнал үзенең кызыгын өч көннән дә, өч айдан да югалтмый. Шуңа күрә һәр санын җыеп барам, пөхтә итеп саклыйм. Әкиятләр, башваткычлар бигрәк тә ошый. Рәссамнардан Айдар абый, Надир абый, Рушан абый, Илдар абый рәсемнәре бик мавыктыргыч. Башка рәссамнар да бик оста, исемнәрен атамаганга үпкәләмәсеннәр. Бизәлешкә мин бик таза «5»ле билгесе куяр идем.

Лиана ӘМИРХАНОВА, 11 яшь. Казан.

● Башлангыч класс укытучысы буларак, мондый журнал турында күптән хыяллана идем. Татарстаннан читтә яшәгәнлектән, «Салават күпере»н даими сатып алу мөмкинлеге юк. Казанда укучы кызлар аша әлегә журналның биш санын ала алдым. Журналны мин дәрестә куллану өчен һәм дүрт яшьлек улыма дип алдырам. Улыма иң элек үзем укыйм. Аннан ул тагын апасыннан, әтисеннән укыта. Тәкъдимнәрем: Муса Җәлил, Абдулла Алиш әсәрләрен, әдәплелеккә, тәүфикълы булырга өйрәтүче хикәяләрне ешрак бастырсагыз иде. Башваткычлар, табигатьне сакларга өндәп язылган әсәрләр дә бик кирәк.

Сария РАНГУЛОВА. Пермь өлкәсе, Барда районы Түбәнавыл мәктәбе укытучысы.

● «Кирлемән киңәшләре»н укырга, рәсемнәр карарга яратам. Алга таба мәзәкләрне күбрәк бастырыгыз, яме? Төрле-төрле әйберләр ясарга да өйрәтсәгез иде.

Алсу ХАҖИЕВА, 10 яшь. Ютазы, Бәйрәкә.

Рәссам Фәрит ЯКУПОВ



● «Салават күпере» журналын без дүрт яшен тутырып килүче кызыбыз Алинә өчен алабыз, беренче битеннән алып азагына кадәр бергәләп укыйбыз, рәсемнәренә карап, үзебезчә хикәя яисә әкиятләр чыгарып, бер-беребезгә сөйлибез. Кызыбыз күңеленә ошаган шигырьләрне, тиз әйткечләрне, такмакларны бездән кабат-кабат укытып, яттан сөйләргә өйрәнә. Чыга башлаганына әле күп тә түгел, ә журнал инде яраттырды, гел үзенә тартып тора. Нindirәк язмалар кызыксындырганны аерым атап әйтә алмыйбыз, һәр язма үзенчә кызык, үзенчә файдалы. Рәссамнарыбызның да берсенең исемен атап, икенчесенең исемен төшереп калдырасы килми, чөнки һәр рәссам булган бар көчен, табигать биргән байлыгын нәни дусларына җиткерергә тырыша. Аларга аерым бик-бик зур рәхмәт. Журналның бизәлешенә без бары иң яхшы, иң югары бәяне генә бирә алабыз. Изге ак юл сиңа, «Салават күпере»!

ФӘТХИЕВЛАР гаиләсе. Чаллы шәһәре.

● Мин журналны һәрвакыт өчәр итеп алам. Берсе — үземә, аның миңа бик зур ярдәме тия (яследә эшлим). Икенчесен авылга, энемнең өч яшьлек кызы Язгөл белән яшь ярымлык улы Илнарга алып кайтам. Олысы: «Апа, матур китап алып кайттыңмы?» — дип сорап тора. Әле алар үзләре укый алмыйлар, аларга әбиләре (әнием) укый. Өченчесен мондагы, Казандагы сеңлемнең улы Айдарга дип алам. Әле ул кечкенә, яшь тә дүрт айлык. Әнисе белән рәсемнәрен карыйлар. Иң беренче таныган рәсеме — песи. «Мияу-мияу»,— дип күрсәтә. Журналның бизәлешенә «5» ле куям. Куярга яраса, «6» лы да куяр идем. Хәер, кем генә начар билге куяр икән шушындый матур журналга. Аның бит кәгазе дә нинди, аның өчен фин дусларга да рәхмәт әйтәсе килә!

Җәвәһирә ВӘЛИЕВА. Казан.

Язмалары югарыда урын алган авторларыбызга һәм юк вакытларын бар итеп журналханәбезгә хат җибәргән башка укучыларыбызга (Лилия ШӘЙДУЛЛИНА. Актүбә; Гөлфинә ВӘГЫЙЗОВА. Мөслим; Рауза ГАДИЕВА. Кукмара; Гөлшат НАСЫЙПОВА. Әлмәт; Гөлнара ГАЛИЕВА. Чаллы; В. МӨХӘММӘТДИНОВА. Әлмәт; Луиза ФӘРШАТОВА. Уфа; Наилә ИСЛАМОВА. Актаныш; Гөлназ ГАЯЗОВА. Балтач; Гөлназ ВАХИТОВА. Мөслим; Элеонора ХАҖИЕВА. Әлмәт; Маннур МУСИН. Арча... һ. б., һ. б.) олуг рәхмәтләребезне юллыйбыз. Сезнең кебек укучыларыбыз булганда, «Салават күпере» мәңге картаймыйча озак яшәр, иншалла!

© «Салават күпере», 1992 ел.

Син бик әйбәт, Кеша!

Без аны бик еpактан, Африкадан алып кайттык. Нәни генә иде әле ул. Жако нәселле тутый кошлар зур гәүдәле булалар. Кеша да үсте. Без аның читлеген баштан ук радиоалгыч янына куйган идек. Ул Кешага иптәш булып көне буе сөйләп тора. Тутый кошыбыз биш ел эчендә кеше тавышына охшатып сүзләр, җөмләләр әйтергә өйрәнде. Аның «сүзлек запасы» хәйран бай.

Ишектә кыңгырау шалтыраса, иң әлек Кешага җан керә. Ул: «Кем бар?» — дип кабатлый башлый. Тутый кошыбыз иртән үз янына керүче белән: «Исәнме!» — дип исәнләшә, өйдән чыгып китүчегә: «Сау бул!» — дип кала. Кич белән: «Йокларга вакыт!» — дип искәртә һәм: «Үп мине!» — ди.

Кеша уйнап туймый торган тутый кош. Ул таганда атынырга ярата, юындырганда дөнья рәхәте кичереп тик тора, душ астыннан чыкмас та иде.

Кешаның яраткан ризыклары — чикләвек һәм алма. Ашаганнан соң ул томшыгын сөртергә онытмый. Ә аның томшыгы бик зур, көчле. Ул бервакыт читлек чыбыкларын кимереп өзеп, форточкадан урамга да чыгып очкан иде. Без аны көч-хәлләр белән эзләп таптык.

Тутый кошыбыз читлектә генә яшәми. Без аны бүлмәгә дә чыгарабыз. Ул бүлмә буйлап кинәнеп йөри. Диванга менеп вәкарь белән атлап киткәнен күрсәгез! Үзе бит әле бертуктаусыз: «Мин сине яратам!», «Кеша акыллы», «Кеша әйбәт»,— дип сөйләнә...

Без дә акыллы, әйбәт Кешабызны бик яратабыз.

Фирая МИҢҖАНОВА, педагог.
Казан.

Редакциядән. **Тышлыкның беренче битендә — тутый кош Кеша.**



Рәссам Әнвәр ЯКУПОВ

ЛАТИН ЯЗУЫ НИГЕЗЕНДӘ ТАТАР ӘЛИФБАСЫ

БАСМА ХӘРЕФЛӘР	ЯЗМА ХӘРЕФЛӘР	КИРИЛЛИЦАДА БИРЕЛЕШЕ	ХӘРЕФЛӘРНЕҢ ИСЕМНӘРЕ	БАСМА ХӘРЕФЛӘР	ЯЗМА ХӘРЕФЛӘР	КИРИЛЛИЦАДА БИРЕЛЕШЕ	ХӘРЕФЛӘРНЕҢ ИСЕМНӘРЕ
A a	*A a*	А а	А	O o	*O o*	О о	О
B в	*B в*	Б б	БЭ	Ө ө	*Ө ө*	Ө ө	Ө
Ç ç	*Ç ç*	Җ җ	ҖЭ	P p	*P p*	П п	ПЭ
C c	Ч ч	*C c*	ЧЭ	Q q	*Q q*	Қ қ	ҚА
D d	Д д	*D d*	ДЭ	R r	*R r*	Р р	ЭР
E e	Е е	*E e*	Е/Э/	S s	*S s*	С с	ЭС
Ə ə	*Ə ə*	Ә ә	Ә	Ş ş	*Ş ş*	Ш ш	ША
F f	*F f*	Ф ф	ЭФ	Y y	*Y y*	Ү ү	Ү
G g	*G g*	Г г	ГЭ	T t	*T t*	Т т	ТЭ
Ƣ ƣ	*Ƣ ƣ*	Ғ ғ	ҒЫ	U̇ u	*U u*	У у	У
H h	*H h*	Һ һ	ҺЭ	V v	*V v*	В в	ВЭ
I i	*I i*	И и	И			/КӨНБАТЫШ ЕВРОПА ҺӘМ РУС СҮЗЛӘРЕНДӘ/	
J j	*J j*	Й й	КЫСКА И	X x	*X x*	Х х	ХА
K k	*K k*	К к	КА	Z z	*Z z*	З з	ЗЭ
L l	*L l*	Л л	ЭЛЬ	W w	*W w*	В в	ВЭ
M m	*M m*	М м	ЭМ	Ƶ ƶ	*Ƶ ƶ*	Ж ж	ЖЭ
N n	*N n*	Н н	ЭН	Ь ь	*ь ь*	Ы ы	Ы
Ņ ņ	*Ņ ņ*	Ң ң	ЭҢ	/МӨ'MIN/	’	Э	/МӨЭМИН/

Cc *Cc*





Dd *Dd*

Ee *Ee*



Рәссам Айдар ҮТӘГӘН



Хәй Вахит

Болында

Болында, болында
Ал чәчәкләр үсәләр.
Ал чәчәкләрне тибрәтеп,
Җылы җилләр исәләр.

Xəj Waxit

Bolьnda

Bolьnda, bolьnda
Al cəcəklər ysələr.
Al cəcəklərne tibrəten,
Çьlь çillər isələr.

Сәхифәнең мөгаллиме — филология фәннәре докторы, профессор Вахит Хаков.

Хәкимҗан ХАЛИКЪ

СЫБЫЗГЫ БОРЫН



Сызгырганны
Ишеткән дә
Бер куян,
«Аучы бу!» — дип
Коты очкан
Куркудан.

Коштай очып
Бара икән
Сукмактан,
Бүре килеп
Чыкмасынмы
Шул чакта!



Куян әйткән:
— Торма болай
Ыжгырып.
Ычкын тизрәк,
Аучы килә
Сызгырып!

«Бетте баш!» — дип
Әйткән дә, ди,
Калтырап,
Чапкан бүре
Куяннан да
Катырак.



Аю килеп
Чыккан икән
Ыжгырып,
— Кач! — дигән ул.—
Аучы килә
Сызгырып.

— Чынлап,— дигән
Ялт-йолт карап
Куян да.
Аю исә
Башын кашып
Куйган да,
Уйлагандай
Нидер эшләп
Карарга,
И тотынган,
И тотынган
Чабарга!..

Хәле бетеп,
Куян калган
Иң артта,
Ялгыз калгач,
Алган, ди, ул
Җылап та.

Йомшап киткән
Борынын да
Сөрткән, ди,
Һәм шуннан соң
Сызгыру да
Беткән, ди.

Ә куянның
Күрсәң шулчак
Көлгәнен!..
Үз борыны
Сызгырган бит,
Күр әле!

Рәссам Алла АЙСИНА



Сөекле

МӨХӘММӘД ПӘЙГАМБӘРНЕҢ ТУУЫ

Гарәбстандагы Кураеш дип аталган илнең башлыгы Габделмоталиб атлы бер хөрмәтле адәмнең угылы Габдулла Мәккә шәһәреннән кәрван белән ерак базарга китә һәм кайтыр юлга чыккач, унсигез яшендә, кинәт вафат була. Габдулланың хатыны Әминә йөкле булып кала һәм көмәне алты айлык вакытта төш күрә. Төшендә аңа бер адәм мондый нәсихәт бирә:

— Йа, Әминә! Һич шикләнмичә ышан ки, син кешеләрнең иң игелеклесе белән йөклесең. Ул тугач та аңа Әхмәт вә йә Мөхәммәд исеме куштыр!

Һиҗрәттән илле ел элек, Нәүширван хөкүмәтенең кырык икенче елында, Рабигыльәүвәл аеның уникесендә, ягъни 571 елның 20 апрелендә, башкөндә — дүшәмбедә, табигатьнең иң гүзәл чагында, һавадан нурлар явып торганда, бәхетле вә нигъмәтле мизгелдә Аллаһның сөеклесе туып, дөньяны бәхетле итте. Мөбарәк пәйгамбәребез, туар-тумас, башын сәҗдәгә орып:

Рәссам Надир АЛЬМЕЕВ

Пәйгамбәребез

— Лә иләһә илләл-лаһү, инне Рәсүлү-лаһи: Аллаһтан башка тәңре юктыр вә мин аның рәсүлемен, ягъни илчесе булырмын,— диде.

Фәрештәләр бәбәйне сөннәткә утырттылар, кендеген кистеләр, юындырдылар. Ул арада күкләрдән җиргә пәрдә кеби оп-озын бер комач сузылып төште һәм бер тавыш ишетелде:

— Аны кешеләр күзеннән яшерегез!

Җир йөзе бер очтан икенче оҷына нур белән тулды. Соңра нур эченнән бер ак болыт аерылып, баланы алып, күздән югалды. Болыт киткәндә янә теге тавыш ишетелде:

— Аны көнчыгыштан көнбатышка кадәр гиздерегез. Пәйгамбәрләрнең туган җирләренә алып барыгыз, бәрәкәт хасил булсын вә ул аларның догаларын алсын. Бөтен галәм исеме-җисеме белән аны танысын!

Бераздан соң пәйгамбәр әфәндебезне биләүләнгән килеш кире китерделәр. Аның кулында өч ачкыч бар иде: пәйгамбәрлек, җиңү вә дан ачкычлары.



Сәхифәне, төрек язучысы Рәхим ЭР язган «СӘВГЕЛЕ ПӘЙГАМБӘРЕМ» китабыннан файдаланып, БАТУЛЛА әзерләде.

’92

ЯНВАРЬ

	6	13	20	27
	7	14	21	28
1	8	15	22	29
2	9	16	23	30
3	10	17	24	31
4	11	18	25	
5	12	19	26	

ФЕВРАЛЬ

	3	10	17	24
	4	11	18	25
	5	12	19	26
	6	13	20	27
	7	14	21	28
1	8	15	22	29
2	9	16	23	

МАРТ

	2	9	16	23	30
	3	10	17	24	31
	4	11	18	25	
	5	12	19	26	
	6	13	20	27	
	7	14	21	28	
1	8	15	22	29	

АПРЕЛЬ

	6	13	20	27
	7	14	21	28
1	8	15	22	29
2	9	16	23	30
3	10	17	24	
4	11	18	25	
5	12	19	26	

МАЙ

	4	11	18	25
	5	12	19	26
	6	13	20	27
	7	14	21	28
1	8	15	22	29
2	9	16	23	30
3	10	17	24	31

ИЮНЬ

1	8	15	22	29
2	9	16	23	30
3	10	17	24	
4	11	18	25	
5	12	19	26	
6	13	20	27	
7	14	21	28	

ИЮЛЬ

	6	13	20	27
	7	14	21	28
1	8	15	22	29
2	9	16	23	30
3	10	17	24	31
4	11	18	25	
5	12	19	26	

АВГУСТ

	3	10	17	24	31
	4	11	18	25	
	5	12	19	26	
	6	13	20	27	
	7	14	21	28	
1	8	15	22	29	
2	9	16	23	30	

СЕНТЯБРЬ

	7	14	21	28
1	8	15	22	29
2	9	16	23	30
3	10	17	24	
4	11	18	25	
5	12	19	26	
6	13	20	27	

ОКТЯБРЬ

	5	12	19	26
	6	13	20	27
	7	14	21	28
1	8	15	22	29
2	9	16	23	30
3	10	17	24	31
4	11	18	25	

НОЯБРЬ

	2	9	16	23	30
	3	10	17	24	
	4	11	18	25	
	5	12	19	26	
	6	13	20	27	
	7	14	21	28	
1	8	15	22	29	

ДЕКАБРЬ

	7	14	21	28
1	8	15	22	29
2	9	16	23	30
3	10	17	24	31
4	11	18	25	
5	12	19	26	
6	13	20	27	



Рәссам Айдар УТӘГӘН
Андрей ДРЯХЛОВ һәм Николай АЛЕКСАНДРОВ фоторәсеме

Салават күпере





Сирай суы

Тиз әйткеч

Сирайның суынмаган суына Сөббух суын салсаң, Сирайның суынмаган суы сиксән сигез секундта суына.

Рәссам Фәрит МУЛЛАХМӘТ

БУЛГАН, ДИ, БЕР КЕШЕ

Борын-борын заманда бер кеше булган,
Яланаякка балта кигән, ди.
Билбавына өч чаңгы кыстырган,
Урманга барган да юкә янында бау каезларга тотынган.
Анда бар икән, ди, өч үрдәк,
Ул үрдәктә күлләр йөзеп йөргән,
Бу кеше аны күргән.
Өч таяк кисеп алып аткан,
Берсе барып җитмәгән,
Берсе үтеп киткән,
Берсе үрдәкләргә тигән, ди.
Үрдәкләр бик каты курыккан:
Берсе алды белән,
Берсе аркасы белән очкан,
Берсе арты белән күлгә чумган.
Күл очып киткән дә
Агач башына кунган, ди.

ТАБЫШМАК ӘЙТӘМ — ТАП

Җәй буе ял итәләр,
Кыш тәпиләп китәләр.

(Чаңгылар).



ҖЫЙДЫК КҮП ҖИЛӘК

Такмаза

Борын-борын заманда,
Әти дә тумаганда,
Киттек урманга,
Җиләк җыярга.
Гыйнуар ае иде,
Җыйдык күп җиләк —
Булды бер чиләк.
Алып кайтырга
Җиктек бер ишәк.



Аучы кәҗәләр

Такмак

Иртән торып тышка чыксам,
Сыерлар кар көриләр.
Ә кәҗәләр, мылтык тотып,
Куян атып йөриләр...







Балык кышын туңамы?

Якшәмбе көнне Азамат белән Нияз чаңгыга басып урманга киттеләр. Бара торгач, урманны аркылып чыгып, елга өстенә килеп чыктылар. Нияз чаңгы таягы белән бозга тукылдатып алды да:

— Сулар туңгач, балыклар нишли микән? — дип куйды.— Әллә алар да, кошлар җылы якка очкан шикелле, җылы якларга агып китәләрме?

Алардан хәйран еракта бер балыкчы шәйләнә иде. Малайлар аннан сорарга булдылар.

Калын тун, олтанлы итекләр кигән, мыеклары бәстән агарган бабайның кәефе шәп иде — берничә балык эләккән. Ялгыз утыру ялыктырган, ахрысы, бер сорауны да җавапсыз калдырмады ул.

— Елга-күлләрдә кыш көне дә тормыш кайный. Кыш бабай боз астына яшергәнгә, без аны күзәтә алмыйбыз гына. Су бит тоташ катмый, аның өске өлеше генә бозга әверелә. Шушы боз һәм аның өстенә яуган кар елга-күлләрне юрган кебек каплап, төпкә кадәр туңудан саклый. Боз судан җиңелрәк, шуңа күрә ул суның өске катламында барлыкка килә. Боз судан авыррак булган булса, елга-күлләр тоташтан бозга әверелер иде. Ә балыклар туңмыйлар, кыш көне дә тыныч кына яши бирәләр. Тик кайвакыт аларга һава җитми. Шуңа күрә кешеләр бозны тишеп бәке ясыйлар, балыкларга җим сибәләр...

Кинәт бабай кулындагы кармак сабы дерелдәп куйды. Каба! Малайлар рәхмәтләрен әйтеп китәргә ашыктылар. Шундый әһәмиятле мизгелдә балыкчыга комачаулау ярыймы соң!

Сәхифәне Фоат ХӘМИДУЛЛИН алып бара.

Рәссам Алсу ТИМЕРГАЛИНА







«Ялгыз йорт».
Наташа ГРИГОРЬЕВА, 13 яшь.
Казан.





«Чыршы бәйрәменә килегез!»
Айгөл МӨХӘММӘТШИНА, 11 яшь.
Киров өлкәсе, Чавал.



«Алтын көз».
Булат МОСТАФИН, 8 яшь.
Казан.
«Дуслар».
Зарина ГЫЙЛАҖЕТДИНОВА, 6 яшь.
Казан.



Нияз АКМАЛ

КИЛӘЛӘР ДӘ...

Киләләр дә гел әйтәләр:
— Әнисенә охшаган!
Күрәләр дә гел әйтәләр:
— Әтисенә охшаган!

Нәрсә генә әйтсәләр дә,
Һәммәсенә ышанам:
Әнигә дә охшаган мин,
Әтигә дә охшаган!

Фәрит ЯХИН

ӨСТӘЛНЕ ҮТЕП КИТКӘН

Нурсибә гөл үстерә:
Су сибә дә су сибә...
— Су сипсәм,— ди,— зур булып
Үсәләр,— ди Нурсибә.

Энесе карап тора,
Сүзен колакка элә.
Тустаганны тотырып,
Су эчә дә су эчә.

— Инде эчем күпте,— ди.
— Нигә һаман үсмим,— ди.
— Бүген дә үсмәсәм,— ди,
— Бүтән сөт тә эчмим,— ди.

Су эчте дә су эчте —
Гөл инде зуп-зур үсте.
Булат кына кечкенә,
Үсәлми бит һич кенә.

Сөт тә эчеп карады,
Татлы су да калмады...
Әһә, үскән бит инде,
Үтеп киткән өстәлне.



Рәссам Рүзәл ВӘЛИЕВ



Борынгы бабаларыбыз

КУБРАТ ХАН



Кубрат ханны бүгенге татар халкының бабаларының бабасы дип әйтергә була. Аның әнисе угро-фин кабиләсеннән, әтисе Дулу нәселеннән — төрки.

Кубрат хан 584—642 елларда яшәгән дигән тулы булмаган мәгълүматлар бар. Ошбу хан Таман ярымутравында, Тын елгасының түбәнге өлешләрен дә кертеп, Бөек Болгар дәүләтен төзи.

Кубрат хан төркиләре Тәңре диненә, ягъни Күк-Кояшка табынганнар. Тәңре диненә табынган һәр төрки иртән чыгып килгән кояшны каршы ала торган булган. Әләмнәре ак төстә, аңа кояш сурәте төшерелгән.

Кубрат ханның биш угланы һәм бер кызы булган. Угланнары: Батбай, Кодрак, Аспарух, Балкыр, Аслан. Кызы: Чәчкә.

Кубрат хан хазарлар белән сугышта һәлак була.

Рәссам Рушан ШӘМСЕТДИН


Сәхифә Мөсәгыйть ХӘБИБУЛЛИН хикәяләвендә бирелә.



Син автобуста (трамвайда яки троллейбуста) утырып барасың. Янәшәңдә бер кулына авыр букча тоткан әби (яки бабай) басып тора. Син аның бик карт булуына да, еш-еш сулыш алуына да игътибар итмә. Җыерчыклы кулы тоткан авыр букчага да карамаска тырыш. Сагыз чәйнәвеңне бел. Тәрәзәгә караган бул, йокымсыраганга салыш. Йә булмаса, кулыңдагы рәсемле китабыңны укыгандай ит.

Бер мизгелгә генә үзеңне әлеге әби (яки бабай) урынына куеп кара. Сиңа шундый рәхәт, күңелле булыр.

Әллә киресенчәме?!.



Рәссам Юрий ДЕНИСОВ

Әниләргә
һәм
нәниләргә

Басыйр РАФИКОВ

БИШЕК ҖЫРЫ

Әлли-бәлли-бәү тирбәтә
Бишегеңне җир шары.
Йокласын дип, син, күз нурым,
Төн сүндергән утларны.

Әлли-бәлли-бәү, йолдызым,
Йоклаган елга, күлләр.
Йоклаган чәчәк, үләннәр,
Шаярып йөргән җилләр.

Әнә, кошлар да йоклаган,
Туктатып очар юлын.
Тәмле-тәмле төшләр күреп,
Йокла син дә, күз нурым.

Сандугачлар җыры белән
Уятыр сине иртә.
Уйнарга дип уенчыгың —
Нәни курчагың көтә.

Әлли-бәлли-бәү, кошчыгым,
Бул таянычым минем.
Тыныч йокла, дәү булып үс,
Ак юлың алда синең.

Рәссам Фәрит ШАКИРОВ

Сәләвәт күпере

1 (23) — 1992

ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАР БЕРЛЕГЕ ИДАРӘСЕ һӘМ СОВЕТ-ФИН УРТАК ПРЕДПРИЯТИЕСЕ «ПОИНТ» ЖУРНАЛЫ

1990 ЕЛНЫҢ МАРТ АЕННАН БИРЛЕ ЧЫГА

Баш мөхәррир
Зиннур ХӨСНИЯР

Җаваплы сәркатип
Фирая БӘДРЕТДИН

Бүлек мөхәррире
Ләбиб ЛЕРОН

Бизәлеш мөхәррире
Айдар ҮТӘГӘН

Исәп-хисап бүлеге
Розалия ЗАРУБИНА

Тышлыкта Андрей ДРЯХЛОВ һәм Николай АЛЕКСАНДРОВ фоторәсеме

Татарстан газета-журналлар нәшрияты. Казан, Декабристлар урамы, 2.

«Салават күпере» ежемесячный журнал Правления Союза писателей ТССР и Советско-Финского Совместного предприятия «ПОИНТ» (на татарском языке). Основан в 1990 году.

Адрес редакции: 420012, г. Казань, ул. Комлевā, 14. Редакция журнала «Салават күпере».

Производствога бирелде 20.12.91 ел. Басарга кул куелды 05.02.92 ел. Кәгазь форматы 84×108 1/16. Басма табак 1,0 (2,1). Нәшер-хисап табагы 3,09. Офсет ысулы белән басыла. Тиражы 35 мең данә. Заказ И-611.
Бәясе 1 сум 50 тиен.

Мактанчык Бытбылдык

Г. Тукай әкияте буенча



Бытбылдык берзаман диңгез ярына килде һәм җәнлек-җанвар, кошкорт алдында мактанып: «Мин хәзер бу диңгезне яндырам!» — диде.



Хәбәр шул ук сәгатьтә хайваннар дөньясына таралды һәм барчасы бу хәлне күрергә дип диңгезгә юл алды.



Яңалык кешеләргә дә ишетелгән булса кирәк. Кешеләр дә балык шулпасы ашарга чапты, бер кулларында — кашык, берсендә — икмәк.



Тамашачылар килеп бетте, һәммәсе дә диңгезнең яна башлаганын көтте. Барчасы күзләре талганчы суга карый, ә ул ни янмый, ни кайнамый...



Һәй, бытбылдыккамы соң инде дөньяны таңга калдыру, диңгез хәтле диңгезне яндыру! Аптырагач, ул күзен йомып очып китте, дөньяга мактанчык дигән даны чыкты.



Кулыңнан эш килмәсә, күкрәгеңне киереп йөрмә һәм алдан мактана күрмә!

Бәясе 1 сум 50 тиен

Индекс 73953